ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

_11.07.2022 Мөслим авылы № 282

**«Җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 338 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Прокурорының 12.04.2022 ел, № 02-08-01-2022 протесты буенча, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «җир кишәрлеген арендага, сатуларда милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 29.07.2021 ел, № 338 карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.8.2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 20 пунктчаны өстәргә:

20) «дәүләт яисә муниципаль милектә булган җир кишәрлеге, әгәр җир кишәрлегенә карата, капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә (электр белән тәэмин итү челтәрләреннән тыш) тоташтыру (технологик тоташтыру) мөмкинлеге турында мәгълүмат булмаса, җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган очраклардан тыш, аукцион предметы була алмый»

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru к

3. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнгән.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. Ф. Салихҗанов**